| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>ЧЕРЕМШАНСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>**СОВЕТ ЧЕРЕМШАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>**ЧИРМЕШӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |
| Улица М.Титова, дом 7, Черемшан село, 423100 | М.Титов урамы, 7 йорт, Чирмешән авылы, 423100 |

тел./факс 8(84396)2-52-30 email: Cmn.Cmn2@tatar.ru

**№ 101** **13 ноябрь 2023 ел**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Чирмешән авыл җирлеге Советы**
**карары**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 16 ноябрендәге №9 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 78 статьясының 1 пунктының икенче абзацының гамәлдә булуын туктату турында» 2023 елның 31 июлендәге №389-ФЗ Федераль законына, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Чирмешән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Советының 2020 елның 16 ноябрендәге №9 «Җир салымы турында» карарының «Салым ставкалары» 2 статьясындагы 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «2) торак фонды һәм (яки) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары белән биләнгән җир кишәрлекләренә карата 0,3% (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамый торган күчемсез милек объектына туры килә торган җир кишәрлегенең бер өлешеннән тыш) яки торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш);».
2. Әлеге карар 2024 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң бер ай узгач кына.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең мәгълүмати

стендларында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Р.Т.Айбатов